СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

*25 июнь, 1997ел.*
*ЧӘРШӘМБЕ*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.*

*№ 68 (8080)*

*Бәясе билгеләнгәнчә*

# КЫЛНЫ КЫРЫККА ЯРЫР ЧАК

## «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

Авылдагы күпсанлы эшләр арасында бүген терлек азыгы хәзерләү барыбер үзәктә тора торганы. Чабу -җыю техникасын тулы әзерлектә тоткан хуҗалыкларда соңгы бер - ике аяз көнне күпьеллык үләннәрне чабу һәм аларны беренче чиратта печәнгә җыеп алуда нәтиҗәле файдаланалар. Нәтиҗәдә Мичурин исемендәге, «Татарстан», Әлмәт, «Кондырча» хуҗалыкларында коры печән запасы чагыштырмача ярыйсы ук. Район буенча күпьеллык үләннәрнең өчтән береннән артыгы чабылды. Киекле, Хафизов исемендәге, «Алга», «Рассвет» хуҗалыкларында андый мәйданнар чагыштырмача күп. Соңгы бер көндә Киекле, Муса Җәлил исемендәге, «Родина», «Заветы Ильича», «Якты Күл» һәм башка кайбер хуҗалыкларда 5 - 20шәр тонна печәнне эскерткә куя алдылар. Район буенча коры печән запасы бер көндә 56 тоннага артты.

Бер үк вакытта башка төр мал азыклары хәзерләү дә игътибардан читтә калырга тиеш түгел. Кызганычка каршы, соңгы вакытта витаминлы үлән оны ясау агрегатларының күбесе тик тора, яфрак азык җыю да әллә ни түгел.

Кыр эшләренең башкалары да чиратка куелырга тиеш түгел. Бигрәк тә шикәр чөгендере басулары зур игътибар сорый. Татлы тамырны сирәкләүне тәмамлаган хуҗалыклар күп булса да, ул эшне ахырына җиткерә алмый азапланучылар да бар әле. Аларның кайсыларына районның төрле оешмаларыннан ярдәмгә киләләр килүен, әммә арада авыл халкын бу эшкә оештыра алмаучылар да бар.

Илдар чагыштырмача яшь кеше әле. Шуңа да карамастан, тормышта үз урынын тапты инде ул. «Норлатнефть» НГДУсының икенче нефть һәм газ чыгару цехында оператор булып эшли башлавына быел 5 ел тулды. Тырышып эшли ул. Һәрхәлдә, егетнең эшенә канәгатьсезлек белдерелгәне юк. Моңа үз - үзенә таләпчән, хезмәтенә карата җаваплы булуы белән ирешә ул.

Илдар Әхсәнович даими эзләнеп эшләүче кеше. Лаеш авыл хуҗалыгы техникумының юридик факультетын тәмамлап, укуын читтән торып институтта дәвам иттерүе дә шул хакта сөйли.

Илдарның үзешчән рәссам булуы да коллективка яхшы мәгълүм. Шуңа да цехта плакат - биркалар ясарга, нәрсә булса да бизәргә кирәк булса, җитәкчеләр иң элек аңа мөрәҗәгать итәләр. Шәрәпов исә һичнинди үтенечне кире какмый.

- Бөтен яклап килгән егетебез ул безнең,- ди аның турында цех начальнигы Җ.Мөхәммәтшин да.



**Рәсемдә: И.Шәрәпов.**
**Н.КВАШНИНА фотосы.**

# БЛАГОУРКАДА ЭШ КЫЗУ

Мамыкка барып җитәрәк уңда калучы зур кыр Благоурка дип атала. Кыр патшасы - кукуруз, шикәр чөгендере, бодай үсә биредә. Урман култыгында күпьеллык үләннәргә дә урын калган хәтта. Әле кайчан гына ямь - яшел булып утырган Благоурканың нәкъ менә шул мәйданы икенче төс алган бүген. Костер үләне, люцернаның шактый мәйданы теземнәргә салынган. Басу күрке булып берничә кибән утыра инде.

- Яңгырлар комачауламаса биредә эшне күптән тәмамлаган булыр идек инде,- ди басуда эшләүчеләрнең берсе - Александр Зайчиков, - югыйсә, һәр көнне маневр ясап, теземнәрне әйләндерүдән башлыйбыз.

Әнә, без биредә булган көнне дә «Агрохимсервис»тан ярдәмгә килгән ЛТЗ - 55 тракторына тагылган ГВК тырмалары белән теземнәр әйләндерү белән мәшгуль иделәр. Василий Григорьев эш фронты булмаганлыктан печән чаптыручы Зайчиков янында әвәрә килә иде.

- Төштән соң теземнәрне җыярга керешәчәкмен инде,- диде Василий дәдәй, - аннан соң инде Иванга да эш булачак.

Ә Иван Колотилин «Беларусь» тракторына көйләнгән кибән өйгеч белән эшли икән.

Гомумән, 147 гектарлы бу басуда барлыгы 4 берәмлек техника гына печән хәзерли. Төп эшне Александр Зайчиков башкара: ЮМЗ - 6 тракторына көйләнгән КС - 2,1 чапкычы белән үләннәрне теземнәргә сала ул. Көн саен 10 - 15 гектарда эш башкара. Берничә көн Геннадий Павлов ярдәм иткән. Хәзер инде Александр бу мәйданда эшне үзе тәгәлләргә исәпли.

- Вакытны заяга уздыру безнең өчен кулай түгел,- ди Зайчиков, - хезмәт хакын башкарылган эш күләменә бәйле рәвештә алабыз без.

Анысы шулай, «Сөлчә»не «Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалык итеп алып биредә җитди реформалар башлагач хезмәт хакын башкарылган эш күләменә бәйле иткәннәр. Шуңа тиз дә, сыйфатлы да эшләргә тырышалар механизаторлар. Тик менә соңгы вакытта ешайган яңгырлар гына эшкә аяк чала, печәнчеләрнең кәефен кыра бераз.

- Яңгыр үләннәр өчен бик кирәк инде ул. Шулай да бу басу без көткән уңышны бирмәс ахрысы быел...

Механизаторлар печән кибәннәре буенча фараз йөртәләр булып чыкты. Элеккеге елларда Благоуркада печән кибәннәренең саны 19 - 20гә җитә торган булган, ә быелгы теземнәр буенча исәп тотсаң, ул кадәр булмас, мөгаен, дип борчылалар печәнчеләр. Хафаланырга урын бар шул: үләннәрне никадәр карап, тукландырып торсаң да, «картайган» мәйданнардан котылу юлын тапмасаң, зур уңышка өмет итмә инде.

Анысы хуҗалыкның Благоуркада гына түгел, башка участоклардан да терлек азыгы хәзерләү мөмкинлекләре бар әле. Әнә, узган ел аны шулкадәр күп итеп туплаганнар иде ки, хәтта агымдагы елга да калды. Быел да сынатмаслар, шәт.

... Басуда киеренке хезмәт кайный бүген. Темпны югары тотып эшләгәндә, бер көн эчендә кышның әллә күпме вакытына җитәрлек терлек азыгы хәзерләп буласын беркем дә исеннән чыгармый.

**Р.ГИНЯЕВА.**

# КАТНАШТЫЛАР ҺӘМ ҖИҢДЕЛӘР

Район сабан туе быел моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә ямьле, әзерлекле узды, һәртөрле спорт ярышлары да зур активлык белән үттеләр. Шушы көннәрдә район сабан туе үткәрү комиссиясе бөтенхалык бәйрәмендә спорт ярышларына йомгак ясап, җиңүче командаларны билгеләде.

***Беренче урынга - 458 очко җыеп «Норлатнефть» НГДУсы*** командасы чыкты. Алар бу очколарны гер спортында, таяк тартышу, армрестлинг, милли көрәш, ат чабышында җыйдылар. Бу командага ярышлар шарты нигезендә 30 млн. сум премия тапшырылды.

***Икенче урынны - 328 очко белән «Кондырча» КХАсы*** яулады. Хуҗалык ат чабышында, аркан тарту, милли көрәш, армрестлингта бик актив булды. Алар 20 млн. сум премия белән бүләкләнделәр.

***Өченче урында - «40 лет Победы» КХАсы*** (324 очко). Алар милли көрәш, ат чабышы, армрестлинг, гер күтәрүдә күп очко җыйдылар. Командага 15 млн.сум премия тапшырылды.

IV урынга район мәгариф бүлеге, V гә - Кузнецов исемендәге КХА чыктылар. Ярышларда шулай ук шикәр заводы, Зүзәй нефть промыселы, Хафизов исемендәге КХА командаларының да активлыгы билгеләп үтелде.

## Автобуслар йөреп тора




Авыл халкы өчен социаль ихтыяҗлы мәсьәләләр арасында мөһим һәм кирәкле мәсьәләләрнең берсе - район үзәге белән элемтә. Беренче чиратта, регуляр автобус хәрәкәте күздә тотыла. Шөкер, ул хакимияткә яңа башлык килгәч үсеш алды, кайбер җирләрдә яңалары ачыла. Шулай итеп зур һәм кечкенә авылларда яшәүчеләрнең берсе дә үзләрен зур дөньядан аерылган дип хис итмиләр.

## Ике иске плюс бер яңа

Соңгы бер-ике ел эчендә Н-Октябрь автопредприятиесе Яңа Норлат - Тумба маршрутын ачу мөмкинлеген тапты. Шулай итеп, район үзәгеннән иң ерак булган авыл белән элемтә тәэмин ителде. Норлат - Салдакай, Норлат - Тимошкино маршрутлары исә «яңартылды». Билгеле инде, финанс проблемалары бу маршрутта автобус хәрәкәтен көн саен йөртүгә комачаулый, әмма халык соравы буенча безнең шоферлар билгеле көндә бу авылларга ким дигәндә Зәр рейс ясый.

Шәһәрдә пассажирлар йөртүгә килгәндә, монда да проблемалар норлатлылар файдасына хәл ителә. Гамәлдәге Кормыш - шикәр заводы - аэропорт маршрутыннан тыш, җомга, шимбә, якшәмбе көннәрендә азык - төлек һәм промышленность базарлары арасында ике автобус йөри. Сүз уңаенда әйткәндә, бу барлык маршрутлар арасында иң табышлысы.

**И.КАНӘФИН,**
**автовокзал начальнигы.**

## «Элемтәче» дә, «Квант» та

Район элемтә бүлегенең «Элемтәче» кибете норлатлылар яратып йөри торган сәүдә ноктасының берсе иде. Бу көннәрдә бүлекнең тагын бер кибете ишекләрен ачты. «Квант» дип атала ул. Кибет нефтьчеләрнең яңа микрорайонындагы АТСның яңа бинасында урнашкан. Сәүдә ноктасы заман таләпләренә җавап бирерлек итеп, зур зәвык белән җиһазланган. Биредә киң ассортиментта канцелярия товарлары, мәктәп өчен кирәк - яраклар, элемтә җиһазлары һәм төрледән - төрле бизәкле обойлар сатыла. «Квант» шулай ук азык - төлек продуктлары белән дә сәүдә итә.

## Бүген - соңгы көн!

**Бүген - «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газеталарына икенче яртыеллыкка язылуның соңгы көне. 23.400 сумыгызны кызганмыйча куйсагыз, ел ахырына кадәр райондагы хәлләр турында хәбәрдар булып торачагыгыз көн кебек ачык - анысына без ышанабыз.**

***Дус булыйк, «Дуслык»лы булыйк!***



# Норлат мае - иң тәмлесе

***Норлат сөт- май заводының продукциясенә әлеге бәяне күптән түгел Казанда булып үткән республика смотр - конкурсында республиканың иң зур белгечләре бирде. Норлат мае тәме, төсе, консистенцияләрнең тиешле дәрәҗәдә булуы, гомумән, барлык күрсәткечләр буенча да 20 комбинат арасында беренчелекне яулады.***

Дөрес, Норлат сөт- май заводының уңышы беренче ел гына түгел: менә 7 ел рәттән заводлылар үз продукцияләрен Казанга алып барып компетентлы жюри һәм башка районнардагы коллегалары хөкеменә тапшыралар һәм җиңү белән кайталар.

Бер яктан , гаҗәп тә: завод үзе яңа түгел, аңа быел 43 яшь, югары сыйфатлы продукция җитештерү өчен шартлары да заман таләбенә туры килерлек түгел кебек. Әмма юк, җайланмалар ел саен диярлек яңартыла тора, нәтиҗәдә, эш авыр булса да, шартлары яхшыртыла, диләр заводта. Ул гына түгел, быел заводның продукцияне эшкәртүчәнлеге күпкә артты. Былтыр шул вакытта тәүлегенә 94 мең тонна сөт кабул ителеп эшкәртелгән булса, быел ул 130 мең тоннага җитте (чагыштыру өчен Чистайның яңа төзелеп, заманча җиһазландырылган заводы 60 тонна, ә Яр Чаллыда 100 тонна продукция кабул итәләр).Продукция ассортименты да әкрен булса да арта тора, бүгенге көндә завод сөт- катык, каймак, эремчек, май, казеин чыгара һәм санап kителгәннәрнең һәркайсын шәһәрлеләр яратып алалар. Ул республика дәүләт стандарты йөзендә дә ышанычлы предприятие булып санала, тикмәгә генә күп кенә предприятиеләрнең продукциясенә сертификатны өч айга, бер елга биргәндә , Норлатлыларга аны өч елга биреп куялар.

Продукциягә заявканы безнең район кибетләре генә түгел, Чаллы Башы, Самара, хәтта Ульяновск өлкәләреннән дә алалар.

- Бигрәк тә катык, каймакны яраталар алар,- ди, заводның өлкән мастеры, «РСФСР азык индустриясенең атказанган хезмәткәре Асьят Далгатовна Камалетдинова. «Катыкның тәме буенча да конкурс оештырылса, сез беренче булыр идегез, мөгаен»,- дим аңа. Җавап итеп ул горур елмая. Дәүләт стандарты таләбе буенча катыкны шешәләрдә чыгарудан пакетларга күчкәндә шикләре зур булуын әйтә. «Норлат халкы, пастеризацияләнгән, сыек катыкны кабул итәрме, юкмы?» янәсе. Ләкин озак та үтми, шикләрнең урынсыз булуы ачыклана. Әлбәттә, заводның уңышында 28 нче елын коллектив тормышына биргән, һәр продукцияне чыгару алдыннан бөтен нечкәлекләрен исәпкә алучы, кыскасы, аларны халык яратып ашарлык тәмле итүче белгеч-технолог Асьят Далгатовнаның өлеше аз түгел. Технологик контроль бүлеге начальнигы Надежда Викторовна Кудряшова, санитар врач Тамара Александровна Колпакова- бу фидакарь белгечләр дә продукциянең сыйфатлылыгы өчен күп көч куялар.

-Гомумән, коллектив бердәм, барлыгы 100 кеше эшли бирдә, һәркайсы 10 ар-20 шәр ел эшләүче оста куллы хатын-кызлар, хезмәтнең иң авыры да алар җилкәсенә төшә,- ди А. Д. Камалетдинова. -Май ясау бүлеге эшчеләре Гөлсинә Газизова, Рәхимә Мусина, Людмила Камышина, Вера Кульметьева, пакетларга тутыру цехында Мәдинә Закирова, аппаратчылар Клавдия Иванова, Сания Яруллина - болар һәммәсе дә заводның ышанычлы, тырыш кешеләре.Менә лабораторияне заводның йөрәге дип атыйбыз, анда эшләүче тәҗрибәле лаборантлар Йосыпова һәм Исламгалиева Флюралар турында мактау сүзләре әйтәсе килә.Яшь лаборантка Роза Нәфиева да өметле күренә. Эшләрнең иң нечкәләре хатын-кызлар кулында булса да ир-атларның да күпчелеге җылы сүзләргә лаек. Баш инженер Михаил Иванович Ермилов, әле яңа баш механик Юрий Васильевич Корышев, слесарь- төзәтүче Нәҗип Әхмәтшин үз вазифаларын тирәнтен аңлап, җиренә җиткереп башкаралар.

Продукциянең сыйфатлылыгын Асьят Далгатовна район авыл хуҗалыгы идарәсе белән тыгыз бәйләнештә эшләүләре нәтиҗәсе, дип тә саный, чөнки чимал сыйфатлы булмый торып соңгы продукциянең сыйфатлылыгына беркайчан да ирешеп булмаячак.

Тагын бер продукция турында әйтеп үтмичә ярамый: завод тәүлегенә 1,5 тонна казеин эшкәртә һәм аны Димитровградтагы арадашчысы аркылы чит илгә сата. Тик сатып алучылар кыйммәтсенәләр ди. Моңа җавап итеп, яхшы әйбер арзан булмый, диләр заводта. Ул бит дәүләт стандарты буенча тулысынча югары сорт белән бара. Бу продукция әлегә безнең илдә кулланылыш тапмаган, менә чит илдә аңа ихтыяҗ зур икән: төрле ризыкларга өстәмә итеп кулланалар. Казеин җитештерү бик авыр хезмәт, шуңа карамастан ,Миннегөл Вәлиева һәм Фәния Таҗиева аңардан курыкмыйлар.

Сөт-май заводы турында кыскача менә шулар. Кырыс финанс шартларына карамастан, предприятие конвейрлары ел әйләнәсенә бертуктаусыз эшли, ул гына түгел, республикада иң сыйфатлы продукция чыгаруга да ирешә. Ә майга килгәндә, ул һәр гаиләнең өстәлендә бар, кабып карагыз, чынлап та тәмле бит...

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

● <u>Басылганга кире кайтып</u>

## АЕРМА - ҖИР БЕЛӘН КҮК АРАСЫ

**«Дуслык» газетасының быелгы 5 нче санында «Төрнәс» КФХАсында дуңгызчылыкта хәлнең канәгатьләнмәслек булуы турында «Дуңгызларга... дуңгызларча караш» дигән тәнкыйть материалы бастырган идек. Шулардан соң хәл үзгәргәнме? Әлеге сорау безне янә шушы хуҗалыкка китерде.**

- Хуҗалыкта дуңгызчылыкка игътибар кимү барыбызны да борчый иде инде,- диде баш зоотехник Н.И.Шугаев - шуңа хезмәтне оештыруның төрле формаларын барлап, үлчәүгә салып карадык...

Һәм, төрнәслеләр «Рассвет» КФХАсы тәҗрибәсен җентекләп өйрәнеп, шуны нигез итеп алалар.

Икенче төрле итеп әйткәндә, дуңгызлар караучы һәр кеше ассоциация белән килешү төзи. Ә анда бер шарт билгеләнә: һәр анадан 6 баш дуңгыз алырга. Шуннан артыгы - үзеңә. Телисең икән үзең асыра, теләмәсәң - сат, теләсәң югарырак бәя белән хуҗалыкка тапшыр. Терлекчеләр, килешүгә, кем әйтмешли, ике куллап риза булалар. Фермага бригадир итеп билгеләнгән Нина Гордеевна Сиякина да хезмәтне оештыруның бу алымын ошата һәм үзеннән торган төп эш - малларны каплатуны оештыруга да җитди алына. Югыйсә, элеккеге елларда бөтен маллар да ирекле каплатыла торган булган Нина Гордеевна моның эшкә никадәр зыянлы булуын яхшы аңлый һәм нәселле ата дуңгызларны аерым, аналарын аерым туплап, аларны каплатуга әзерли башлый.

Хуҗалык җитәкчелеге зооветбелгечләр белән киңәшеп, дуңгызларны җәйге лагерьларга күчерү хәстәрен дә алдан күрә. Югыйсә, лагерь була торып та, менә инде ике ел дуңгызлар җәй буе сасы, юеш абзарларда ябылып ятарга мәҗбүр иде. Шуңа да кардалар ремонтлана, төзәтелә. Майда исә барлык дуңгызлар да җәйге лагерьларда яши башлыйлар. Терлекчеләр исә май - июнь айларында балалата да башлыйлар мыркылдыкларны.

Билгеле инде, бу җаваплы чор зур тырышлык таләп итә алардан. Шуңа да кайчак вакыт белән дә санашмыйча эшләргә туры килә. Аның каравы, нәтиҗә начар булмый: иркендә балалаган дуңгыз «нәниләрен» дә таптамый, яшел чирәм өстенә тәгәрәп киткән бер дуңгыз иркендә, җылы кояш астында күзгә күренеп тернәкләнә. Шуңа үлем - китем дә юк дәрәҗәсендә. Әнә, Әлфия Кәлимуллина үз карамагындагы һәр баш малдан 10ар дуңгыз баласы алды. Аның белән янәшә кардада эшләүче Галина Сологубныкы 9 баш. Любовь һәм Ирина Фролова, гаилә подряды нигезендә эшләүче Анна, Ольга һәм Минталип Камаловлар группаларында да дуңгызлар 9арны балалады. Тулаем ферма буенча 100 анадан 913 бала алынды. Яшь үрчем җәмгысе 1600 башка җыелды. ( узган елның шул чорында 813 баш иде). Июль башларында терлекчеләр килешүдә каралганнан артык алынган дуңгыз балаларын үз өйләренә алып китәчәкләр. Хуҗалыгыңа дуңгызларны көтүе белән куалап кайтып, аларны тере акчага әйләндерү чарасын күрсәң, ничек инде киләчәктә дә шуңа омтылып, кызыксынып эшләмисең ди?!

Билгеле инде, белгечләр кардада калган барлык малларны да исән-имин үстереп , тиз көрәйтү өчен чараларны аз үткәрмиләр. Рацион да шуны күздә тота. Әнә, имезүче аналарга көн саен 6 килограмм исәбеннән катнаш азык, калганнарына күп итеп эремчек суы, аертылган сөт бирелә.

4 еллап хәрәкәт итмәгән азык цехы да эшкә җибәрелгән. Биредә дуңгызлар өчен ботка пешерелә. Хәзер һичкайчан улакта калмый ул.Шуңа маллар да тиз көрәяләр. Баш зоотехникның дәүләткә тапшырылачак итнең яртысы дуңгызныкы булачак дип ышандыруы да буш хыял түгел, ә реаль мөмкинлек булуына инанасың.

Гомумән, бүген дуңгызчылыктагы эшләрне кышкы чордагысы белән чагыштырсаң аерманың җир белән күк арасы кадәр булуына инанасың.

**Р.ГИНЯЕВА.**

*Сез сораган идегез?*

## «Доверие» ышанычсыз булды

**1994 нче елның мартында хатыным белән икебезнең ваучерны «Доверие» инвестиция фондына тапшырган идек. «Доверие» булгач, димәк, ышанычлы дип уйлап дивидендлар алырга өметләндем. 1996 нчы елның беренче кварталында 1995 нче елның беренче яртыеллыгы өчен икебезгә 11 мең сум дивиденд килде. Шуннан соң ни акча күрмәдек, ни акция.**

**Ваучерларын «Доверие»гә салган башка авылдашларым да шулай буш кул белән калдылар. Киләчәктә без дивиденд алуга исәп тота алабызмы?,- дип шалтыратты безгә Урта Камышлы авылыннан сугыш һәм хезмәт ветераны К.КРАСНОВ.**

Хөрмәтле Кузьма Васильевич! Сезнең соравыгызга җавап табу өчен әллә ничә инстанциягә шалтыратырга туры килде безгә. Шунысы мәгълүм булды: ваучерлар кабул итү чорында «Доверие» инвестиция фондының вәкаләтле вәкиле ваучерларны район үзәк шифаханәсе поликлиникасында кабул иткән. Хәзер аның кайда булуы мәгълүм түгел. Һәрхәлдә, без аны эзләп шалтыраткан инстанцияләрдә бу вәкил турында төгәл мәгълүматлар табылмады. Сезне һәм шулай ук «Доверие»гә ышанган башка кешеләрне шулай дип кенә тынычландыра алабыз.

Фәһимә Гомәрова - теләсә нинди эшне җиренә җиткереп башкара торган кеше. Профилакторийда сменалы сыер савучы булып эшләгәне бар аның. Бозаулар да карый. Җәен шикәр чөгендере эшкәртергә чыкмаган елы да юк.

Менә быел да кыш көннәрендә карап үстергән бозауларын көтүгә озатты да, шикәр чөгендере сирәкләүгә чыкты ул.

Гомумән, Фәһимә нинди хезмәткә алынса да, аны намус белән үти, эшнең сыйфатын һәрчак беренче планга куя.



Рәсемдә: «Кондырча» КХА терлекчесе Ф.ГОМӘРОВА.

Н.АЗИЗОВ фотосы.




## Кашпировский кайда?

Кайберәүләр, Кашпировский кайда икән?- дип сорыйлар. Ул исән - сау. Польшада, Чехиядә, АКШта эшләп кайткан. Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты чагында Мәскәүдә фатиры булган, әмма пропискасы беткән. Үзенең әйтүенә караганда, даими тору урыны юк. Күбрәк Чехиядә яши, хатыны шуннан.

*Эссе!*

# Су коенасы иде

***Тышта эссе. Су чәчрәтеп, рәхәтләнеп су коенып, тәнгә ял бирәсе килә. Әмма безнең норлатлылар белә: шәһәрлеләр өчен җәйге көндә коену урыны табу, проблема. Әле нинди!.. Язмаларыбыз да шулар хакында.***

## 1. Бассейн бар ла ул...

Заманында зур булмаса да шәһәр өчен бер дигән бассейн бар иде. Аңа нигез исә алтмышынчы еллар азагында, нефтьчеләрнең әле иске микрорайоны төзелгәндә салына. НУРБ җитәкчелеге шәһәрдәге беренче бакчачылык ширкәтләренең берсе булган «Нефтьче» ширкәте белән Дружба урамының арткы өлеше арасыннан 350ләп квадрат метр җирне бүлеп алып биредә 25 метрга 75 метрлы бассейн төзергә булалар. Озак та үтми ,НУРБ үз көче белән бу эшне башкарып та чыга. Бассейнның тирә - яклары төзекләндерелә: территория коймалана, агачлар утыртыла, чишенү, ял итү өчен беседкалар корыла. Ә инде объектның һәрчак төгәл җавап тотарлык хуҗасы булсын өчен НУРБ бассейнны үзенең тампонаж цехына тапшыра. Тампонажчылар исә бассейнда суны да алыштыралар, төбен дә чистартып - карап торалар. Ремонт, территорияне чистарту эшен исә нефтьчеләр җыйнаулашып башкара торган булалар. Җәйләрен исә биредән кеше бетми: балалар иртә таңнан кичке караңгыга кадәр рәхәтләнәләр. Коенам дисәң- суы җылы, чиста, төбе такыр, уйныйм дисәң - урыны бар, ял итим дисәң - ышыгы, беседкалары...

Туксанынчы еллар башында районның ул вакыттагы җитәкчелеге бассейнны шәһәр карамагына алып, аны һәр предприятие уртак көч белән ремонтларга тиеш дигән карарга килмәсәләр, бассейн бүген дә элеккегечә тулы сулы булыр иде, мөгаен. Баштарак, ремонттан соң берничә ел даими булмаса да бассейнга әледән - әле су җибәреп торалар, соңгы 4 елда биредә тулы тынлык. Дөрес, узган һәм аннан элеккеге елларда биредә әлеге дә баягы шәһәрнең барлык предприятиеләре ярдәме белән капиталь ремонт үткәрү планлаштырыла. Без, үз чиратыбызда, биредә күпме финанс тотылуын санауны максат итмәдек. Әмма шунысы хак: биредә эш бассейнның төбен бетонлау, ян - якларына вак ремонт үткәрүгә генә кайтып кала. Һәм, иң кызганычы, шуннан соң ни эш дәвам иттерелми, ни бассейнга су агызылмый. Бассейн исә хуҗасыз объект буларак «тилмереп» тора: кәкре куллылар аның шул халәтеннән файдаланырга өлгерделәр. Кайсысыдыр туалет тартмасын «сугып» киткән. Чишенү - киенү өчен ясалган тимер беседкадан да җилләр искән хәтта. Гөмбәчекләрнең исә түбәләре «кыйшайган». Территориянең соңгы тапкыр чүп - чардан кайчан чистартылганын хәтерләүчеләр дә сирәктер, мөгаен.

Бассейнның язмышы белән кызыксынып байтак инстанцияләргә шалтыратырга туры килде безгә. Әмма, ни кызганыч, анык җавап бирүче табылмады. Димәк, шәһәрдә бердәнбер булган бу объект быел да җәй буе сусыз торачак, димәк, балаларыбыз һаман да безне утка салып, үзләренең гомерләрен куркыныч астына куеп, Кондырча елгасына йөриячәкләр.

## 2. Кондырчада коенырга ярый

Кондырча - коену өчен иң якын су чыганагы. Шәһәр үзәгеннән җәяү анда биш километрлап атлыйсы.

Шулай да, Кондырча су керү өченме соң? Дөресрәге, анда коену урыны бармы?

Боргаланып - боргаланып агучы текә ярлы, мул сулы Кондырча елгасы буенда халык мыж килә иде ул көнне. Җәяүләп тә, машина - мотоцикл белән килүчеләре дә бар иде араларында. Бераздан килеп туктаган ике автобустан 60 - 70ләп бала төште тагын. Болары - район мәгариф бүлеге каршындагы «Яшүсмер» профиль лагеренда ял итүчеләр булып чыкты. Озакламый елга буенда буш урын калмады да диярлек. Кем каян - берәү сөзәгрәк, икенчеләре текә ярдын төшеп, агач - куаклар арасыннан елга эченә йөзеп кереп китте.

- Кондырчада коенырга ярыймы?

- Ярый,- дип җавап бирде безнең әңгәмәдәшебез, үзе әйтүенчә, иртәнге сәгать 9дан бирле биредә коенып ятучы АТП микрорайоны «егете» - 12 - 13 яшьләр чамасы Ваня Павлов. - Ярамаса берәр билге куелыр иде...

- Башка урын булмагач, шунда киләбез инде,- дип сүзгә кушылды аның дусты Руслан Гыйльманов та. Сүз уңаеннан әйткәндә, мөстәкыйль рәвештә, бирегә үзләре генә килгән балалар бик күп иде бу көнне. Ярый ла, лагерьдагыларының яннарында тәрбиячеләре бар. Ә калганнары? Караучысыз су коенган балаларның нәкъ менә биредә суга батулары аз булдымыни? Ә батудан һичкем гарантияләнмәгән: зур шәһәрләрдәге кебек суга батучыларны коткару хезмәте турында хыялланырга гына кала бит безгә.

## 3. ... Ярамый

Яраса берничә җирдә булса да коену өчен махсус урын булыр иде, мөгаен. Әйтик, сөзәгрәк ярга ком җәю, ышыкланыр өчен «гөмбәләр», кием алыштыру урыннары куелыр иде анда. «Бакалык» ясау, икенче төрле итеп әйткәндә, сай урында кече яшьтәгеләр өчен аерым урын бүлеп алу да зарар итмәс иде. Елга һәм яр буйлары өйрәнелеп, куркыныч урыннарга кисәтү биркалары, чүп - чар өчен махсус контейнерлар куелса, Кондырчада коену бүгенге көндәге кебек куркыныч булмас иде. Ләкин, кызганычка каршы, моның белән шөгыльләнергә теләүче түгел, кызыксынучы да юк. Элеккеге ОСВОД юк хәзер, балалар - яшьләр оешмалары, мәгариф бүлеге, шәһәр Советы елга буйларын карауны үз вазифасы санамый.

- Монда коену куркыныч икәнен дә беләм, ата - аналарым да шул турыда кисәтәләр, шулай да башка урын булмагач, коенырга бирегә киләм,- диде безнең чираттагы әңгәмәдәшебез Илназ. Аңа башка яшүсмерләр дә кушылып китте. Бер көн элек биредә су коенганда бер иптәшләренең аздан гына су төбенә китмәвен сөйләделәр.

Балалар балалар инде. Каникул вакытларында да эссе көннәрдә бөркү өйләрендә ята алмыйлар шул алар. Бассейнда су булса да монда килеп йөрмәсләр иде әле алар. Ә ул булмаганда Кондырча буена төшмәүдән тыеп кара син аларны... Бусы - мәсьәләнең бер ягы. Алдарак телгә алынган таләпләр үтәлсә дә, елга буенда ял иткәндә тимер - томыр, пыяла кисәкләренә басып, тән җәрәхәтләре алучылар да сирәгәер иде, мөгаен. Юкса, әле быел гына да, нәкъ менә Кондырчада коенганда җәрәхәтләнгән, имгәнгән күпме кеше шифаханәгә мөрәҗәгать итте инде. Табиблар ярдәменнән башка үзләре дәваланганнары күпме тагын? Анда - санда чүп контейнерлары кую азмы - күпме дәрәҗәдә булса да елга буйларын чистарак тотарга (елга буена эчеп, тәртип бозар өчен генә түгел, ял итәр өчен махсус килүчеләр дә бар бит әле) мөмкин булыр иде, мөгаен.

**РЕДАКЦИЯДӘН: Хөрмәтле норлатлылар! Язмабыздан аңлагансыздыр инде, шәһәребез халкына җәйге көннәрдә рәхәтләнеп, һичнидән курыкмыйча су коену өчен су табу зур бер мәшәкать, чөнки бездә моның өчен махсус урын юк. Югыйсә, тырышканда моның өчен әллә ни зур чыгым да тотасы түгел: бассейнга су җибәр - рәхәтләнсен балалар. Кондырча буенда коену өчен махсус урын булдыру да зур проблема тудырырлык түгел. Ахыр чиктә, берничә дистә мең кешесе булган Норлат турында бара бит сүз.**

**Р.ГИНЯЕВА.**

*Булган хәл*

# ОЧРАШТЫЛАР...



Юл бик шома булмаса да, Михаил машинаның тизлеген киметмәде.

- Кара аны, дус кеше, очып чыгып, машинадан ук ожмахка әләгүебез бар бит, - дидем мин аңа.

- Чит планета кешеләрен күреп рәсемгә төшереп калырга өлгерергә кирәк бит безгә.

Барасы җиребезгә килеп туктагач, яныбызга ун - унике яшьлек балалар җыелды. Коля, Толя, Гришаның безгә нәрсә турындадыр әйтергә телләре бик кычытып торганлыгы сизелә иде.

- Я, нәрсә соң ул?- дигәч,

- Әнә тегендә ул,- дип төртеп күрсәтте ак чәчле малай.

- Машина белән кереп буламы соң анда?

- Юк, чокырлар, куаклыклар анда...

«Москвич»ыбызны авыл кырыендагы йорт янында калдырып Каравыл Тавы итәгенә таба атладык. Юлда малайлардан нәрсә күргәнлекләре турында сораштык.

- Иң беренче булып минем әби күргән,- диде Коля.

- Минеке дә,- дип җөпләде аны Гриша.

- Кайчан күргәннәр соң алар аны?

- Җиләк җыярга баргач...

- Алар безгә бу турыда әйтү белән без шунда чаптык,- диде Коля,- аннан шалтыраттык...

- Ул чит кунакларны үз күзегез белән күрдегезме соң сез?

_ Юк. Алар төшеп утырган урынны гына. Әллә нинди аңлашылмый торган түгәрәкләр бар анда,- диде Коля.

- Җир шәп - шәрә,- дип өстәде Толя.

- Ә түгәрәкнең тышкы ягында таш таптык,- дип сүз кыстырды Гриша.

- Ниндиерәк, зурмы?

- Куян башы кадәр булыр.

Тау итәге буйлап тиз бардык. Ниһаять, килеп тә җиттек. Чыннан да түгәрәк бар иде ул җирдә, җире дә шәп- шәрә.

- Монда тагын бер түгәрәк бар!- дип кычкырып җибәрде Толя.

Без Михаил белән бер - беребезгә карашып алдык. Һич аңлый алмыйбыз: нәрсәдән икән соң бу түгәрәк. Күрәсең, бер генә тәлинкә утырмаган монда.

- Төнлә чит планета кешеләренең монда фонарь яндырып йөргәннәләрен күргәннәр, - дип сүз кыстырды сүзчән малай.

- Нәрсәдер шакылдаганны да ишеткәннәр.

- Миша, урынны фотога төшереп алырга кирәк,- дим мин.

***

***Балалар гына түгел, без, олылар да ул урыннан аптырашта калып кайттык.***

***Борылышта безгә бер карт очрады. Кара кәҗә җитәкләгән иде ул. Без инде карттан сораштырырга гына җыенган идек, аның кулындагы кәҗә арканлый торган бауны һәм казыкны күргәч, хәлнең нәрсәдә икәнлеге үзеннән үзе аңлашылды.***

**Ф.ҪАВГАЧЕВ.**

# ШИГЪРИ ТӘЛГӘШЛӘР

**М.УСМАНОВА**

***Авылдан шәһәргә килгән әби монологы***

Сагышлардан торган бу дөньямның
Табалмыймын нигә ямьнәрен,
Туган якның суларына җитми
Эчкән суларымның тәмнәре.
Нефть катнаш суга, хлор кушкан,
«Шифалы су бирә» авызны,
«Кара алтын» дигән шул байлыкны
Агызды икән кайсы явызы?..
Ят - брамат монда карчыклар да,
Исәнләшә белми кешеләр,
«Исән генә яшисеңме?»- диеп,
Хәл белергә керми күршеләр.
Тәрәзәләрендә тимер челтәр,
Ишекләре - калын тимердән.
Авыллардан килгән карт - карчыклар
Таш эчендә шулай тилмерә.
«Кая калды икән киң кырларда
Татлы тамыр иккән чакларым,
Эх, димичә эшләп бирер идем
Ике түгел, дүрт, биш гектарны».
Гәпләшәләр монда карчык - корчык.
Карашлары моңсу, сагышлы.
«Туган нигезләрдән мәхрүм калдык,
«Язмышмы бу, әллә каргышмы?»
Чибәр кызлар, ягымлы хатыннар
«Прогулка» йөртә Этләрен,
Вәкарь белән үтәп этләренең
Ихтыяҗы төшкән этләрен.
Кибетләре тулы этләр өчен
Муенсалы, затлы чылбырлар,
Этләр өчен витаминлы азык -
Җаны теләгәнен сайлап ал.
Этләр өчен килде шәп замана,
Ә кешеләр һаман зарлана,
Ак икмәккә акча җитми кайчак -
Кара икмәк, диләр, файдага.
Авыллардан килгән чибәр кызлар
«Тулай йортта» ялгыз картая,
Сәрхүш чакта алар карта сала -
Насыйп яры төшми картага.
Яңа хәбәр һәр көн радиодан: -
«Үтергәннәр япь - яшь егетне»,
«Көчләгәннәр үсмер кыз баланы»
- Кем туктатыр шундый этлекне?
Ярларыннан ташып ага Кама,
Дулкыннары усал, ярсулы,
Кешеләргә тәүфыйкъ, шәфкать теләп
Сәҗдә кыла авыл карчыгы.

**З.РӘХМӘТУЛЛИНА**

***

Кайчан бәхет өләшәләр -
Иртәләпме, киченме?
Сылуларга, мутларгамы,
Я уңганлык өченме?
Бәхетле буласың килсә
Таңнан ук торасымы?
Әллә җиде ырым белән
Тозаклар корасымы?
Учка салалармы аны,
Җангамы, тырыскамы?
Мөлаемга тиешме ул?
Усалга, кырыскамы?
Кош сыман канатлымы ул,
Яз сыман нурдан мәллә?
Шатлыктанмы, сөюдәнме,
Я тоташ моңнан мәллә?
Кайчан бәхет өләшәләр?
Кайда чират аласы?
Бәрелә - сугыла бәхет эзли
Җирдә адәм баласы...

# Сәламәтлек



## ТАШЛАРДАН КОТЫЛЫЙМ ДИСӘГЕЗ...

Бавырдан һәм үт куыгыннан ташларны чыгару буенча үз тәҗрибәм белән уртаклашасым килә. Бала чагымнан ук минем уң кабырга астыннан чәнчү сизелә иде. Һәм менә моннан ике ел элек ультратавыш тикшерүе үт куыгында бик күп ташлар җыелганын күрсәтте. Мин медицина әдәбиятын, дәвалауның гадәти булмаган алымнары буенча китаплар укый башладым. Надежда Алексеевна Семенованың киңәшләренә тукталдым һәм аларны нигез итеп алдым. Бер ел буена бавырга һәм үт куыгына дүртәр тапкыр чистарту үткәрдем. Бәләкәй генә борчак зурлыгыннан алып ногыт борчагы кадәрле алты йөзгә якын таш чыкты.

Күп кенә танышларым минем үрнәгемә иярде. Барысының да нәтиҗәләре әйбәт. Ә хәзер үт куыгын һәм бавырны чистарту системасы турында. **Беренче һәм икенче чистарту алдыннан** мин өч көн ач тордым. **Өченче һәм дүртенче чистарту арасында** бер ай вакыт үтте, ә ашамыйча тору бары бер тәүлек кенә булды. Көне буе ач торганнан соң, 19 сәгатьтә җылыткычны (грелка) бавыр турысына куям һәм аны 21 сәгатькә кадәр тотам. Аңа кадәр 200 грамм зәйтүн мае (оливковое масло) һәм 200 грамм лимон согы әзерлим. 15 минут саен 3 аш кашыгы зәйтүн мае һәм 3 аш кашыгы лимон согы катнашмасын эчәм. Шуннан соң бер нәрсә дә эчмим.

Эчәкләр, иртән гөлҗимеш саркындысы белән җиңелчә генә салат ашаганнан соң, гадәттә, әйбәт кенә эшли.

Ташлар организмнан чыкканда бернинди авыртуны тоймыйсың: алар «эри», май һәм лимон кислотасы тәэсирендә пластилин сыман булып чыга. Аларны зәйтүн маендагы олеин кислотасы эретә. Үсемлек мае да кулланып караган идем, нәтиҗәсе күпкә начаррак булып чыкты.

Ташлар чыккан чакта күңел болгануы ихтимал. Моны ташлар урыныннан кузгалып, эчәкләргә таба юл алды дип аңларга кирәк. Шунысын да әйтим, бавырны кимендә дүрт тапкыр чистартырга кирәк.

Какча гәүдәле ябык кешеләргә беренче чистартуны яз көне яисә көз башында үткәрү яхшырак. Тулы гәүдәлеләргә - елның эссе вакытында, ә калганнарга елның теләсә кайсы вакытында язгы - җәйге - көзге айларда үткәрү әйбәтрәк.

Тагы да бер киңәш. Ач торганнан соң гадәттәге туклануга күчкәндә төрле соклар эчәргә, кәбестә, чөгендер, кишер, алма салатлары ашарга кирәк. Икенче тәүлектә аз гына ит, аннары башка ризыклар ашарга һәм акрынлап гадәттәге азыкка күчәргә мөмкин.

**Г.СӘЙРАНОВА.**

**(Түбән өлкәсендә чыгучы «Яңарыш» газетасыннан).**

## Сатабыз

**Яңа «Днепр» мотоциклы, бәясе килешү буенча.** Адрес: Куйбышев урамы, 24-2.

***

**Казан, катнаш торбалар, ком-гравий катнашмасы, «Темп» төсле телевизор (кыйммәт түгел).** Энгелс урамы, 32.

***




## Төрлесеннән

**1 нче мәктәбне тәмамлау турында Фәйзуллин Руслан Исламович исеменә бирелгән А 1291998 номерлы аттестатны, югалу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**

***

**1 нче мәктәпне тәмамлау турында Миннәхмәтов Рафаэль Ильясович исеменә бирелгән А 1291989 номерлы аттестатны, югалу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**

***

***Корбанов Фәнил Вакифович исеменә техпаспорт табучының 5-25-55 телефоны буенча (Ирекне сорарга) бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен сорыйбыз.***

***

**Киекле урта мәктәбен тәмамлау турында Абрамова Валентина Николаевна исеменә бирелгән 404302 номерлы аттестатны, югалу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**

***Норлат-Октябрь элемтә узелы шәһәр һәм авыл телефон челтәре абонентларын 28 июньгә кадәр телефон өчен исәп-хисап ясауларын сорый. 28 июньнән соң телефон кисәтүсез өзеләчәк, аны яңадан тоташтыру 45 мең сум акча түләгәннән соң гына башкарылачак.***

## Хәл киткәндә витамин кап

**«Поливит» (АКШ)** - һәр кешегә, яшен искә алып, чыгарылган витамин. Иммун системасын ныгыта, ирлек куәтен арттыра.

**«Супрадин» (Швейцария)** - кәефне күтәрә, хәл кертеп җибәрә торган витаминнар җыелмасы.

**Витамакс (Мисыр)** - бик мөһим аминокислоталар, биостимуляторларга бай, күп төрле витаминнарны үзенә туплаган. Йод, фтор, Селен кебек минераллар да кергән. Хатын - кызларга климакс чорында, ирләргә ирлек куәтен арттыру өчен кулланыла. Операциядән соң, радиация нурланышын дәвалаганда бик файдалы.

**Витамакс (АКШ)** - организмның авыруларга каршы торуын тәэмин итә, кәефне күтәрә. Йогышлы авыруларны, анемия, невроз, бавырны, ашказаны җәрәхәтен, эчәк авыруларын дәвалаганда киң кулланыла. Шулай ук кан юллары, атрессклероз, диабет, тире авыруларыннан файдалы. Бу препарат табигый компонентлардан гына тора.

**Сана - сол** - балалар өчен чыгарыла торган витамин. Анда А, Д, Е, С һәм В төркеме витаминнарының бөтенесе дә бар, шикәр юк. Балаларга 6 айдан бирергә була. Табигый бал тәме бар.

## Америка галимнәре ачышы



Америка галимнәре теләсә нинди төркемгә караган донор канын универсаль канга әйләндерә торган ысул уйлап тапканнар.

«Зимкуэст» медицина җиһазлары җитештерү компаниясе ике сәгать эчендә теләсә нинди төркемгә кергән канны универсаль (нульле) канга әйләндерә торган аппарат уйлап чыгарган.

Аппарат бүгенге көндә Бостон шәһәрендә «Бет Израэл» медицина үзәгендә сынау үтә.

## Наркоманнар турында кайгырту

Эстония наркоманнарга түләүсез бер генә тапкыр кулланыла торган шприцлар тарата башлады. СПИДны кисәтү үзәге моны СПИД һәм йогышлы гепатит авырулары таралуны чикләү чарасы буларак үткәрә. Атнасына ике мәртәбә махсус автомобиль Таллинның Ласкамез районына чыга. Үзәк консультантлары наркоманнарга киңәшләр биреп, түләүсез шприцлар тараталар. Үзәк җитәкчесе Нелли Калинова әйтүенчә, Эстония башкаласының бу районында 3 меңгә якын наркоман яши.

## Чит ил косметикасын алмагыз

Мәскәүдә 110 мең долларлык декоратив косметика (күз кабагы буявы, ирен буявы) партиясе брак дип табылды, сатуга чыгарылмады. Алар «Одель Холдинг ЛТД» (Швейцария) - «Мэйбилайн Косметика Корпорейшн» (АКШ) фирмаларында җитештерелгән. Косметик товарларның начар сыйфатлы булуы, витриналарда озак ятып искерүе аркасында 60 мең долларлык «Грэнд Кэньон Эксплорэшн» (АКШ) фирмасы товарлары да брак булып чыкты.

## Банан ашагыз

Бананның файдасы турында әле күпләр белмидер. Аны базарларда да, кибеттә дә алып була. Халык медицинасында банан ашказаны ярасын дәвалау өчен кулланыла. Күптән түгел галимнәр аның күзәнәкләрнең үсешенә, азыкны эшкәрткәндә организм эшләп чыгара торган кислоталарның җимергеч көченнән ашказанын саклаучы лайла бүленеп чыгуга булыша алуын ачыкладылар.

Бананны профилактика өчен көнгә икене ашыйлар.

## 63 яшендә бәби китергән

Америка Кушма Штатларында медицина практикасында беренче тапкыр бер хатын - кыз 63 яшендә бала тапкан. Үзенең үтенече буенча исемен әйтмиләр.

Бала табуда врачларның да ярдәме булган. Бу ананың бик бала табасы килгән. Аңа яшьрәк ананың күкәй күзәнәге күчереп утыртылган. Йөклек чорын булачак ана яхшы кичергән. Баланы ананың корсагын ярып алганнар. Врачларның әйтүенә караганда, ана да, бала да үзләрен әйбәт хис итәләр.



## Җитәкчеләр һәм баш бухгалтерлар игътибарына!

**ТР Хөкүмәтенең «АК БАРС» вәкаләтле банкы Норлат вәкиллегендә расчет счеты (расчет хезмәт күрсәтүе) ачу мөмкинлеге булуы турында хәбәр итә.**

**Банк клиентлары өчен льготалар каралган. Сораулар белән Норлат вәкиллегенә мөрәҗәгать итәргә.**

## Очрашуга чакырабыз



***Илюткино сигезьеллык мәктәбен 1981 елда тәмамлаучылар очрашуы 5 июль көнне 14.00 сәгатьтә булачак.***

## Идел Буе региональ наркология үзәге

***Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.***

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне 1, 15 августта көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә. Заказ N 7187